РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

№24 16 май, 2018

**Түбән Кама шәһәр Советының “Физик затларның милкенә салым турында” 2014 елның 20 ноябрендә кабул ителгән 31нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**
(2015елның 15июнендәге 23нче номерлы, 2015елның 23октябрендәге 17нче номерлы карарлар редакциясендә)

“Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2017 елның 30 сентябреннән гамәлгә кергән № 286-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбән Кама шәһәр Советының “Физик затларның милкенә салым турында” 2014 елның 20 ноябрендә кабул ителгән 31нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә: 2нче пунктның 3 пунктастындагы “бер торак бина (торак йорт)” сүзләрен “бер торак йорт” дип үзгәртергә.
2. Әлеге карарның 2018 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керүен билгеләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А. Р. Метшин